ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 март 2024ел № 1786

Башкарма комитетның 2023 елның 22 декабрендәге 12414 номерлы Карары белән расланган Башкарма комитетының үз компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 22 декабрендәге 12414 номерлы Карары белән расланган Башкарма комитетының үз компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

2) 5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- идарә башлыгы урынбасары.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов